Введено в действие приказом
заведующего МБДОУ
«Детский сад №7 «Рябинушка»
№ 149 от «29» 08.2023 г.

Утверждаю:
Заведующий МБДОУ
«Детский сад № 7 «Рябинушка»
________ И.В. Веретенникова
Рассмотрено и утверждено
на педагогическом совете
Протокол №1 от «29» августа
2023 г.

**ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ
МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
7 нче номерлы «МИЛӘШКӘЙ» БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА
ТАТАР ТЕЛЕ ТӘРБИЯЧЕСЕНЕҢ РУС ҺӘМ БАШКА МИЛЛӘТ
БАЛАЛАРЫН ТАТАРЧА ӨЙРӘТҮ БУЕНЧА
2023 – 2024 УКУ ЕЛЛАРЫНА
ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

(Программа мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартларын күздә тотып, укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде)

**«СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ» БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ
(2 – 7 ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН)**

Программаны төзеде:
балалар бакчасының
татар теле тәрбиячесе
Камалова А.И.

Яр Чаллы шәһәре, 2023нче ел

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз.......................................................................................................

I БҮЛЕК. Максатчанлык
1. Аңлатма язуы...........................................................................................................
1.1. Программаның максаты һәм бурычлары.........................................................
1.2. Программа принциплары...................................................................................
1.3. Балаларның яшь үзенчәлекләре........................................................................
1.4. МББУнең милли составы
1.5. Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр.............................................
1.5 а. Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)
1.5.б. Зурлар төркеме (5-6 яшь)
1.5.в. Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)
1.6. Эш төрләре һәм формалары..............................................................................
1.7. Инновацион эш.......................................................................................................
1.8. Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.................................................

II БҮЛЕК. Эчтәлекле
2.1. Тематик планнар
2.1. а «Татарча сөйләшәбез»
2.1 б «Туган телдә сөйләшәбез»
2.2. Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)...............................................................
2.3. Зурлар төркеме (5-6 яшь)..........................................................................
2.4. Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)...........................................................
2.5. Татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә куллану өчен биремнәр.
2.6. Коррекцион эш
2.7. Ата - аналар белән эш..........................................................................
2.8. Мәктәп белән бәйләнеш.........................................................................
2.9. Педагогик коллектив белән эш................................................................

III БҮЛЕК. Оештыру
3.1. Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар........................................
3.2. Программаны тормышка ашыру өчен материаль техник шартлар........
3.3. Белем бирү мөхитен үстерүнең предметлы – әйләнә тирәлеге.................
3.4. Белем бирү эшчәнлеге челтәре................................................................
3.5. Ел дәвамында эшләнәчәк эшләр циклограммасы
3.5. Әдәбият ..........................................................................................

## Кереш сүз

**Балалар бакчасында рус балаларына татар теле, татар балаларына ана телен өйрәтү буенча эш программасы** (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән **документ булып тора**.

Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде. Әлеге программа максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы, шулай ук, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

**Федераль җирлектә:**

- 29.12.2012елдан № 273-ФЗ «Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган;
- СанПиН 2.4.1.3049-13 «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр» раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2013 ел 15 май 26 нчы номырлы боерыгы;
- «Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру» (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август 1014 нче номерлы боергы);

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законы;

**Мәктәпкәчә белем учредениесе җирлегендә:**

- МБУ Уставы;
- МБУнең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;

Эш программасы өч бүлектән (максатчанлык, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

# I БҮЛЕК. МАКСАТЧАНЛЫК
## Аңлатма язуы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен, «Минем өем» (4-5 яшь), «Уйный – уйный үсәбез» (5-6 яшь), «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» (6 - 7 яшь) проектларын үз эченә ала. Программа шулай ук 2 яшьтән 7 яшькә кадәр булган татар балаларын туган телдә аралашырга, сөйләшергә өйрәтү эшчәнлекләрен дә үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора.

Яңа сүз өйрәткәндә, бала сүзләрне тизрәк истә калдырсын өчен сүзне кат-кат әйттерергә кирәк. Бала сүзне аңламаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә һәм яңа сүз өйрәтү төрле эш формаларында оештырыла. (пышылдап, чәбәкләп, тыпырдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп).

Сүзне шулай ук төрле уеннар кулланып та өйрәтергә була. «Ватык телефон», «Кайтаваз» кебек уеннарда ныгытыла.

Хәтердә калдыру максатыннан «Исемен әйтсәң бирәм», «Мин күрсәтәм, син әйт», «Сорап ал», «Серле кәрзин» уеннар оештырыла

Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә «Бу кем?», «Кем юк?» , «Кәрзиндә нәрсә бар?», «Нәрсә юк?», «Серле янчык», «Әйе-юк», «Дөресен әйт» дидактик уеннары аша куллану да югары нәтиҗә бирә.

Аралаша белү күнекмәләре булдырганда түбәндәге уен ситуацияләрен оештыру бик отышлы: «Әйдәгез танышабыз», «Кунакны чакырып сыйла», «Кибеттә», «Кафеда», «Телефоннан сөйләшү»

## ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ:

**Максат:** Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:**

1. Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.
4. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

## ПРОГРАММА ПРИНЦИПЛАРЫ

- **Коммуникативлылык принцибы** – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.
- **Интеграция һәм дифференциация принцибы** – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау

(аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

- **Күрсәтмәлелек принцибы** – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;
- **Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;**
- **Интегральләштерү принцибы (Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү):** аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.
  Белем бирүне оештыруга интеграцияле якын килү танып белү ысулларының һәм аның сәбәпләренең җыелмасын формалаштыру, танып белү ысулларының бер эшчәнлек төреннән икенчесенә күчүе итеп корыла.
  Интегральләшкән белем бирүнең үзенчәлеге булып аның белем бирүнең үзәге булган бер моһим яки өстенлек итүче эшчәнлек нигезендә төзелүе тора. Бу эшчәнлек белән берләшкән башка эшчәнлекләр белем бирүнең төп эчтәлеген, яшәп килгән бәйләнешләрне һәм балаларның алган белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә куллану мөмкинлекләрен тирәнрәк аңаларга ярдәм итәләр.
- **Дәвамчанлык принцибы** – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;
- **Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы** - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.
- **Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы** - гадидән катлаулыга таба бару
- **Индивидуальләштерү принцибы** - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту.Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

**Белем бирүне комплекслы-тематик принципка корып оештыру.**

**БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ**

- **УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ (4-5 яшь)**.

Бу яшьтә баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуда мөстәкыйльлеге үсеш ала. Балалар өлкәннәр белән практик эшләрдә (йомыш үтәү, күмәк уеннар) аралашуны дәвам итү өстенә интеллектуаль аралашуга да омтылалар. Үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алу өчен балалар өлкәннәргә төрле сораулар бирәләр (Нигә?, Ни өчен?, Нәрсә өчен?). Шулай итеп балалада яңа информация алырга теләк туа. Балаларның сүзлегендә теләктәшлек, кеше хәленә керә белү, кызгану сүзләре барлыкка килә. Яшьтәшләрен үзләренә җәлеп итү өчен балалар аралашуның ситуациясенә карап, интонация, ритм, сүз тизлеген җайлыйлар. Өлкәннәр белән аралашу вакытында сөйләм этикеты кагыйдәләрен үтәп, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, юату, кызгану, кеше хәленә керә белү сүзләрен кулланалар. Бу яшьтә баланың сөйләме бәйләнешле һәм эзлекле була.

- **ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ (5-6 яшь)**.

Алтынчы яшьтә баланың сөйләм үсешендә мөхим үзгәрешләр барлыкка килә.
Авазларны дөрес әйтү бу яшьтә норма булып тора. Балаларда (чит телгә), татар теленә карата кызыксынулары арта, шул телдә сөйләшергә, җырларга, аудио – видеоязмалар тыңларга, телевизион тапшырулар карарга теләкләре үсә. Балалар сөйләмдә гомумиләштерүче, күпмәгънәле сүзләр, антонимнар, синонимнар куллана башлыйлар. Аларның сүзлеге профессияне, социаль учреждениеләрне аңлатучы сүзләр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына

баетыла. Балалар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнеп, мөстәкыйль рәвештә уенлы һәм эшлекле диалоглар төзергә, туры һәм кыек сөйләмне кулланырга өйрәнәләр, тасвирлау һәм хикәяләү монологында геройның хәлен, кәефен, эпитетлар һәм чагыштырулар кулланып, бирергә сәләтле. Балалар үзара кара – каршы сөйләшергә, үзләренә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм шулай ук тиешле репликаны кулланып җавап бирергә сәләтлеләр. Бу яшьтәге балалар уен ситуацияләре, проблемалы – эзләнүле уен ситуациләрен барлыкка китереп, күрсәтмә әсбаплар, мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр.

- **МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ (6–7 яшь)**

Бу яшьтә баланың сөйләме төрле контингет кешеләре (өлкәннәр һәм яшьтәшләре, таныш һәм таныш булмаган кешеләр) белән аралашуга мөмкинлек бирә. Балалар авазларны дөрес әйтү генә түгел, фонемаларны һәм сүзләрне таныйлар. Телнең орфологик системасын үзләштерү аларга исемнәрнең, фигыльләрнең  һәм сыйфатларның катлаулы грамматик формаларын төзергә мөмкинлек бирә.  Чит телгә карат тотрыклы кызыксыну үсә. Мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр, аудио – видеоязмалар, уку – укыту методик комплектларын кулланып предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне һәм сүзтезмәләрне сөйләмдә, аралашуда актив кулланалар. Гади аралашу өчен  кирәк булган сөйләм берәмлекләре белән балаларның лексикасы баей, сүз байлыклары арта.. Бу яшьтәге балалар төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр  төзиләр. Татар телендә сөйләшүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белергә, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышалар. Телне аз белүләренә дә карамастан диалогларда  катнашырга омтылалар. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары бик еш  сөйләмдә катлаулы җөмләләр кулланалар. 6—7 яшьтә баланың сүз байлыгы арта. Диалог төзегәндә бала сорауларга тулы җавап бирергә, үзе сораулар бирергә, әңгәмәдәшен аңларга тырыша. Монологик сөйләм дә актив рәвештә үсә. Балалар эзлекле һәм бәйләнешле итеп сөйли алалар

**«МИЛӘШКӘЙ»  БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА 2016 – 2017 УКУ ЕЛЛАРЫНДА**
**МИЛЛӘТЛӘР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ.**
**ИНФОРМАЦИЯ О НАЦИОНАЛЬНОМ СОСТАВЕ ДЕТЕЙ В ДОУ № 7 «РЯБИНУШКА»**
**НА 2016 – 2017 УЧЕБНЫЙ ГОД**

| ВСЕГО: | ДЕТЕЙ – 288 | ВОСПИТАТЕЛЕЙ – 23 |
|---|---|---|
| В том числе: | | |
| Смешанных браков | 73 | |
| Татарской национальности | 83 | 15 |
| Русской национальности | 113 | 7 |
| Башкирской национальности | 1 | |
| Чувашской национальности | 3 | |
| Другие (расшифровать каждую семью) | 6 – азербайджан<br>3 – мариец, 2 – украинца<br>1 – латыш, 1 – литовец<br>1 – немка, 1 - удмурт | 1 – марийка |

**Балалар бакчасында төркемнәр бүленеше:**

| Яшь саны | Төркемнәр бүленеше | Төркем номерациясе |
|---|---|---|
| 2 – 3 яшь | I – кечкенәләр төркеме | №5, №10 |
| 3 – 4 яшь. | II – кечкенәләр төркеме | №3. №12 |
| 4 – 5 яшь. | Уртанчылар төркеме | №4, №9, №13 |
| 5 – 6 яшь. | Зурлар төркеме | №1, №8, 3!! |
| 6 – 7 яшь. | Мәктәпкә әзерлек төркеме | №2, №6, №7 |
| II – кечкенәләр төркеме | Татар  төркеме | №3 |
| Зурлар төркеме | Татар төркеме | №11 |

**ПРОГРАММА ҮЗЛӘШТЕРҮДӘ КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР**

- **УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ (4-5 яшь)**
  1. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белә.
  2. Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белә.
  3. Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.
  4. Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.
  5. Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.

- **ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ (5-6 яшь)**
  1. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белә.
  2. Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта 107 сүз кулланып татар телендә аралаша.
  3. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана.
  4. Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап, дөрес куллана.

- **МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ (6-7 яшь)**
  1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.
  2. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.
  3. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.
  4. Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

## II БҮЛЕК. ЭЧТӘЛЕКЛЕ

**«МИНЕМ ӨЕМ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН** **УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ**

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА, ЭШ ДӘФТӘРЕ МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| **ГАИЛӘ – 18 СӘГАТЬ (1 – 18)** | | |
| эти<br>әни<br><br>малай<br>кыз<br><br>мин<br>исәнмесез<br>сау булыгыз<br><br><br><br>исәнме<br><br><br><br><br>эт<br>песи<br><br><br><br><br>әйе | – Бу кем?<br>– Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>– Кем юк?<br>– Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).<br><br>– Исәнмесез.<br>– Син кем?<br>– Мин Коля (Оля).<br>– Мин малай.<br>– Сау булыгыз!<br><br>– Исәнме, әни (эти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>– Сау бул, әни (эти, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>– Кем анда?<br>– Мин песи. Мин Мияу.<br>– Кил монда.<br>– Мин эт. Мин Акбай.<br>– Кил монда.<br><br>– Син Коля? | Аудиоязма №1–23<br><br>Дәфтәрдә эш №1–4<br><br>Мультфильмнар:<br>1. «Әйдәгез, дуслашыйк»<br>2. «Качышлы уйныйбыз»<br>3. «Шалкан» |

| | | |
|---|---|---|
| юк<br>сау бул<br><br>әби<br>бабай<br><br><br>әйбәт | – Әйе, Коля.<br>– Син малай (кыз)?<br>– Әйе (юк).<br><br>– Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>– Әйе.<br>– Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>– Юк.<br><br>– Малай?<br>– Юк, кыз.<br>– Кыз?<br>– Әйе, кыз.<br><br>– Хәлләр ничек?<br>– Әйбәт. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 12 СӘГАТЬ (19 – 30)** | | |
| ипи<br>алма<br>сөт<br>чәй<br><br>мә<br>рәхмәт<br>тәмле<br>кил монда<br>утыр<br><br><br>аша<br>эч | – Мә, ипи (алма, сөт, чәй).<br>– Рәхмәт, әби.<br><br>– Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй).<br>– Рәхмәт.<br>– Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля)<br>– Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>– Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт.<br>– Мә, тәмле алма (ипи).<br><br>– Мә, ипи (алма) аша.<br>– Мә, сөт (чәй) эч. | Аудиоязма №24–39<br><br>Дәфтәрдә эш №5–10<br>Мультфильмнар:<br>1. «Тәмле» кибетендә»<br>2. «Азат кунак чакыра» |
| **УЕНЧЫКЛАР – 18 СӘГАТЬ (31 – 48)** | | |
| бир<br>туп<br><br>зур<br>кечкенә<br><br>матур<br>курчак<br><br>куян<br>аю | – Бу нәрсә? – Туп (курчак, куян, аю).<br>– Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>– Мә, курчак (туп, куян, аю).<br>– Бу нәрсә? – Аю (курчак, куян, туп).<br>– Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>– Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).<br>– Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>– Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br>– Аю (курчак, куян, туп)? – Әйе.<br>– Курчак (аю, куян, туп)? – Юк.<br>– Бу нәрсә? – Аю (курчак, куян, туп).<br>– Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br>– Коля, кил монда. Уйна.<br>– Оля, кил монда. Уйна.<br>– Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>– Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>– Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>– Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.<br>– Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>– Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).<br>– Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна). | Аудиоязма №40–53<br><br>Дәфтәрдә эш №11–13<br><br>Мультфильмнар:<br>1. «Паркка сәяхәт»<br>2. «Уенчыклар үпкәләгән»<br>3. «Күңелле уеннар»<br>4. «Акбай һәм Мияу маҗаралары» |

| | | |
|---|---|---|
| хәлләр ничек?<br>уйна<br>пычрак<br>чиста<br>ю | – Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br>– Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>– Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>– Туп ю. – Туп чиста?<br>– Юк, туп пычрак. (Әйе, туп чиста).<br>– Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| **САННАР – 6 СӘГАТЬ (49 – 54)** | | |
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | – Ничә?<br>– Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br>– Ничә малай?<br>– Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>– Ничә кыз?<br>– Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br>– Өч? – Юк.<br>– Ике? – Әйе.<br>– Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>– Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54–60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Мультфильм:<br>1. «Уйный – уйный саныйбыз» |
| **КАБАТЛАУ – 6 СӘГАТЬ (55-60)** | | |
| | | Аудиоязма №61–64<br>Дәфтәрдә эш №16–17<br>Мультфильм:<br>1. «Күңелле ял итәбез» |

## «УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

**ЗУРЛАРТӨРКЕМЕ**

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА, ЭШ ДӘФТӘРЕ МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| **КАБАТЛАУ – 3 СӘГАТЬ (1 – 3)** | | |
| | «Минем өем» проекты буенча | Аудиоязма №1<br>Дәфтәрдә эш №1<br>Мультфильм:<br>1. «Шалкан» |
| **ЯШЕЛЧӘЛӘР – 21 СӘГАТЬ (4 – 24)** | | |
| кишер<br>баллы<br>ничә<br>суган<br>бәрәңге<br>кыяр<br>кәбестә<br>нинди<br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз | – Бу нәрсә?<br>– Кишер.<br>–Мә, кишер.<br>– Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>– Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Рәхмәт.<br>– Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) | Аудиоязма №2–24<br>Дәфтәрдә эш №2– 6<br>Мультфильмнар:<br>1. «Баллы кишер»<br>2. «Уйный-уйный эшлибез»<br>3. «Юл маҗаралары»<br>4. «Кем эшләми, шул ашамый» |

| | | |
|---|---|---|
| ун | – Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>– Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак) | |
| | Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>– Мә кишер(алма), аша. Баллы?<br>– Әйе, баллы. Рәхмәт.<br>– Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>– Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>– Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>– Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>– Рәхмәт. | |
| | – Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>– Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>– Сау бул, Коля. | |
| | – Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>– Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>– Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак. | |
| кызыл<br>сары<br>яшел | – Бу туп. – Туп (алма) нинди?<br>– Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br>– Нинди туп (алма) юк?<br>– Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк. | |
| нәрсә кирәк? | – Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>– Коля, нәрсә кирәк?<br>– Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>– Нинди кыяр?<br>– Яшел (тәмле, чиста) кыяр. | |
| юа | – Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>– Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br>– Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа. | |

| | | |
|---|---|---|
| **АШАМЛЫКЛАР – 6 СӘГАТЬ (25 – 30)** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br>– Нәрсә кирәк?<br>– Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>– Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>– Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>– Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>– Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Аудиоязма №25 – 29<br><br>Дәфтәрдә эш №7, 8<br><br>Мультфильм:<br>1. «Аш бүлмәсе» |
| **САВЫТ – САБА – 6 СӘГАТЬ (31 – 36)** | | |
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | – Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>– Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>– Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>– Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>– (1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>– Мә, (1– 10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>– Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30 – 37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Мультфильм:<br>1. «Өч аю»<br>2. «Чисталыкта– матурлык» |
| **КИЕМНӘР – 6 СӘГАТЬ (37 – 42)** | | |
| күлмәк<br><br>чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br><br>сал<br><br>йокла | яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br>күлмәк (чалбар) юк.<br>– Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>– Нинди күлмәк (чалбар)?<br>– Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>– Ничә күлмәк (чалбар)?<br>– Бер (1– 10) күлмәк (чалбар).<br>– Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>– Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>– Мә, чалбар (күлмәк).<br>– Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>– Курчак, йокла. | Аудиоязма №38 – 43<br><br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Мультфильм:<br>1. «Киемнәр кибетендә»<br>2. «Шаян уенчыклар» |
| **ШӘХСИ ГИГИЕНА – 3 СӘГАТЬ (43 – 45)** | | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | – Хәерле көн.<br>– Мә су, бит (кул) ю.<br>– Бит (кул) чиста.<br>– Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44 – 48<br>Эш дәфтәре №13, 14<br>Мультфильм: «Ни өчен киемнәр югалган?» |
| **ӨЙ ҖИҺАЗЛАРЫ – 3 СӘГАТЬ (46 – 48)** | | |
| өстәл<br>урындык<br>караваt | – Зур (кечкенә) урындык (өстәл, караваt).<br>– Зур аю, мә зур караваt (өстәл, урындык).<br>– Кечкенә аю, мә кечкенә караваt (өстәл, урындык).<br>– Нәрсә кирәк? | Аудиоязма № 49<br><br>Эш дәфтәре №15<br><br>Мультфильм:<br>1. «Маша һәм өч аю» |

| | | |
|---|---|---|
| | – Караваt (өстәл, урындык) кирәк.<br>– Нинди караваt?<br>– Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) караваt.<br>– Мә, зур караваt.<br>– Рәхмәт. | |
| **БӘЙРӘМ «ТУГАН КӨН» – 9 СӘГАТЬ (49 – 57)** | | |
| яратам<br><br><br><br><br><br><br>бар | – Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br>– Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br>– Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br>– Нәрсә бар? – Туп (курчак) бар.<br>– Нәрсә юк? – Туп (курчак) юк.<br>«Бар», «Юк» сүзләрен кулланып «Гаилә», «Яшелчә» «Уенчыклар» темаларын кабатлау. Диалогларны кабатлау. «Кибетле» уеннары. | Аудиоязма №50– 60<br><br>Эш дәфтәре №16–19<br><br>Мультфильм:<br>1. «Туган көн»<br>2. «Кем нәрсә ярата? » |
| **БӘЙРӘМ «САБАНТУЙ» - 3 СӘГАТЬ (58-60)** | | |
| | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>«Гаилә», «Яшелчә», «Уенчыклар» темаларын кабатлау.<br>«Кибетле» уеннары. | Аудиоязма №61– 63<br><br>Мультфильм:<br>1. «Сабантуй бәйрәме» |

## «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА, ЭШ ДӘФТӘРЕ МУЛЬТФИЛЬМ |
|---|---|---|
| син кем<br>хәерле көн<br>тычкан<br>бу кем?<br>бу нәрсә?<br>нишли?<br>йоклый<br>утыра<br><br><br><br>ашый<br>эчә<br><br>нишлисең?<br>ашыйм<br>эчәм<br><br><br>уйный<br>уйныйм<br>утырам<br>барам<br>кая барасың? | – Хәерле көн, Оля (Коля).<br>– Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби).<br><br><br><br>– Песи нишли?<br>– Песи йоклый.<br><br>– Әни нишли?<br>– Әни утыра.<br><br>– Коля нишли?<br>– Коля ашый (эчә).<br><br>– Мияу, нишлисең? – Ашыйм.<br>– Акбай, нишлисең? – Эчәм.<br><br>– Оля (Коля), нишлисең?<br>– Уйныйм.<br><br><br>– Кая барасың? – Кафега барам.<br>– Син нишлисең?<br>-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, | Аудиоязма №1 – 2<br><br>Аудиоязма №3 – 5<br>Дәфтәрдә эш №1<br><br>Мультфильм: «Мияу адашкан»<br><br>Аудиоязма №6<br>Дәфтәрдә эш №2<br><br>Аудиоязма №7 – 8<br>Дәфтәрдә эш №3<br><br>Мультфильм: «Аю баласы дөнья белән таныша»<br><br>Аудиоязма №9– 10<br>Дәфтәрдә эш №4<br><br>Аудиоязма №11<br><br><br>Мультфильм: «Батыр Мияу |

| | | |
|---|---|---|
| син нишлисең? | уйныйм, барам, утырам, йоклый) | һәм куркак Куянкай» |
| сикер-сикерәм | Туп, туп, матур туп. | Аудиоязма №12 |
| | Сикер – сикер, матур туп. | Дәфтәрдә эш №5 |
| сикерә | Куян сикерә (йөгерә). | Аудиоязма №13 – 14 |
| йөгерә | Туп сикерә. | |
| төлке | Песи сикерә (йөгерә). | |
| | Төлке сикерә (йөгерә). | |
| йөгер-йөгерәм | – Йөгер! Син нишлисең? | Мультфильм: |
| | – Мин йөгерәм. | «Тату гаилә» |
| чәк-чәк | – Мин чәк-чәк ашыйм. | |
| өчпочмак | – Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма №15 |
| яшь | | |
| бүре | – Сиңа ничә яшь? – 6 яшь. | |
| керпе | | Аудиоязма №16 – 18 |
| тавык | – Мин бүре. Мин зур, матур, чиста. | |
| әтәч | | Мультфильм: «Юмарт аю» |
| үрдәк | Әтәч зур, матур | |
| | Тавык кечкенә, матур | Аудиоязма №19 |
| | | Аудиоязма №20 |
| чана | – Син кем? | Дәфәрдә эш №6 |
| шуа | – Мин үрдәк. | Мультфильм: «Кафега |
| | | барабыз» |
| шуам | | |
| | | Дәфтәрдә эш №7 |
| бие | Куян чана шуа. | Аудиоязма №21-23 |
| бии | | |
| биим | Мин чана шуам. | Мультфильм: |
| | | «Урманда күңелле уеннар” |
| ак | – Аю, әйдә, бие! | |
| кара | | Аудиоязма №24 |
| | – Оля кызыл шар ярата? | Дәфтәрдә эш №8 |
| | – Юк. | |
| | – Оля яшел шар ярата? | Аудиоязма №25-28 |
| | – Әйе, мин яшел шар яратам. | |
| | | Мультфильм: |
| җырла – җырлыйм | – Син нишлисең? | «Көчлеләр, кыюлар, |
| | – Мин җырлыйм. (җырлыйбыз) | җитезләр» |
| зур рәхмәт | зур рәхмәт | |
| | | Аудиоязма №29-30 |
| китап укый | Кыз китап укый. | Дәфтәрдә эш №9 |
| рәсем ясыйм | рәсем ясыйм – алма ясыйм | Мультфильм: |
| | мәктәп | «Җәнлекләр спорт |
| укыйм | – Кем укый. | бәйрәмендә» |
| | – Мин укыйм. | |
| дәфтәр | | Аудиоязма №31-32 |
| | бик тәмле | |
| | | Аудиоязма №33-34 |
| | Терем – терем, теремкәй, | Дәфтәрдә эш №10 |
| | Зур түгел, кечкенә. | |
| | Теремкәйдә тычкан яши. | Мультфильм: |
| | Теремкәйдә куян яши. | «Циркта» |
| | Теремкәйдә бүре яши. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Алар бик дус.<br><br>– Кәҗә кая?<br>– Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br><br>– Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>– Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>– Мә, кәҗә, ботка аша.<br>– Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | Аудиоязма №35 – 36<br>Дәфтәрдә эш №11<br><br>Аудиоязма №37 – 38<br>Дәфтәрдә эш №12<br><br>Мультфильм:<br>«Шаян кошлар»<br><br>Аудиоязма №39 – 40<br><br>Аудиоязма №41<br>Дәфтәрдә эш №13<br><br>Мультфильм:<br>«Урманда зур концерт»<br><br>Аудиоязма №42 – 44<br>Дәфтәрдә эш №14<br><br><br><br>Аудиоязма №45– 46<br>Мультфильм: «Акбай туган көнгә барырга җыена»<br><br>Аудиоязма №47<br>Дәфтәрдә эш №15<br>Аудиоязма №45, 48 – 49<br><br>Мультфильм:<br>«Мияуның туган көне»<br>Аудиоязма №50<br>Дәфтәрдә эш №16<br>Аудиоязма №51– 53<br>Дәфтәрдә эш №17<br>Мультфильм:<br>«Урман китапханәсендә»<br>Аудиоязма №54– 60<br>Дәфтәрдә эш №18<br>Мультфильм: «Уйный–уйный укыйбыз»<br>Аудиоязма №61-63<br>Дәфтәрдә эш №19<br>Мультфильм: «Урман мәктәбендә»<br>Аудиоязма №64<br>Мультфильм: «Теремкәй»<br>Аудиоязма №65– 66<br>Мультфильм: «Кем нәрсә ярата?»<br>Аудиоязма №67–71<br>Дәфтәрдә эш №20 |

**«Туган телдә сөйләшәбез».**
**Комплекслы тематик план. Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)**

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Танышу | Танышу | 6 |
| 2. | Безнең балалар бакчасы | Аю белән куян кунакка килгән<br>Куянга өй төзибез<br>Курчагым<br>“Үчтеки, үчтеки” такмагын уку<br>Курчакның туган көне<br>Карусельгә сәяхәт<br>Минем матур тубым<br>Әминә Бикчәнтәеваның “Туп-туп, тубыбыз” шигырен уку<br>Уенчыклар кибетендә | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 3. | Көз | Көз җитте<br>Көзге яфраклар<br>”Безнең Алсу “ сериясеннән рәсем карау<br>Яшелчәләр<br>Куян кунакка килгән<br>“Шалкан” әкияте<br>Җиләк-җимешләр<br>Әбидә кунакта<br>Яшелчә бакчасында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4. | Мин - дөньяның бер кешесе | Минем исемем бар<br>Бу — мин<br>Мин –дөньяның бер кешесе | 1<br>1<br>1 |
| 5. | Гаилә | Минем гаиләм<br>Безнең гаилә<br>Өйдәгез дуслашыйк<br>Бу өйдә кем яши?<br>Без чәбәкәй итәбез<br>Уйнарга яратабыз<br>“Гаилә” рәсемен карау<br>Шәйхи Маннурның “Яратам” шигырен уку<br>Өйдәгез уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6. | Кыш | Ап-ак кар ява<br>Алсу урамга җыена<br>Кар бабай ясау<br>Кыш рәсемен карау<br>Кар ява<br>А.Алиш “Куян кызы” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7. | Яңа ел бәйрәме | Яшел чыршы<br>Әминә Бикчәнтәеваның «Беренче адым» шигырен уку<br>Чыршы бизибез<br>Куян чыршы янында<br>Купшы чыршы<br>Без музыка залында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8. | Минем әйләнә - тирәм | Яраткан уен бүлмәбез<br>Алсу бүлмәсе<br>Безнең урам | 1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Безнең апа<br>Алсу авырган<br>Алсуда кунакта<br>Безнең йортта кемнәр яши?<br>Йорт кошлары<br>Хайваннарны чакыру<br>Маэмаем<br>М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку<br>Гав исемле мәче баласы<br>Габдулла Тукай “Гали белән Кәҗә”<br>“Чуар тавык” әкияте<br>Әкияттә кунакта | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 9. | Әтиләр-бабайлар | Зур гаилә<br>Безнең әтиләр һәм абыйлар<br>Бабайга кунакка барабыз<br>Машина<br>Самолет<br>Булатның машинасына гараж ясау | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. | Әниләр-әбиләр | Кибеткә бару<br>Әбидә кунакта<br>Безнең әниләр<br>Алсуны табибка алып барабыз<br>Табибка барабыз. Курчакны йоклату(1) | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 11. | Халык иҗаты | Хайваннарны чакыру<br>”Йомры икмәк” рус халык әкиятен уку<br>“Шалкан” әкиятен уку<br>“Камыр малай” әкиятен сөйләү<br>“Теремкәй” рус халык әкиятен уку<br>Өч аю | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 12. | Яз | Урамда яз<br>Яз җитә<br>Яз<br>Җәнлекләр урманда яшиләр<br>Язгы урманда<br>Агачлар<br>Агачлар<br>Каргалар<br>Кошлар<br>Яз килде<br>Кояш, чык, чык!<br>“Урманда зур концерт” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 13. | Җәй | Бүлмә гөлләре<br>Бүлмә гөлләре<br>Мультфильмда кунакта<br>Куаклар<br>Чәчәкләр<br>Балалар бакчасы ишек алдында<br>Экология сукмагы буенча сәяхәт<br>Су белән уен<br>Мультфильмда кунакта<br>Рәхмәт, җәй!<br>Әнәс Кариның “Чебиләр” шигырен уку<br>Уеннар | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | | 105 сәгать |

**«Туган телдә сөйләшәбез».**
**Комплексный тематик план. Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)**

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Исәнме, балалар бакчасы | Танышу<br>Өйдә кем яши?<br>Мин малай, мин кыз<br>Мияу белән танышу<br>Әйдәгез танышыйк<br>Әйдә дуслашыйк | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 2. | Уенчыклар | Минем яраткан уенчыкларым<br>Минем яраткан уенчыкларым<br>Карусельгә сәяхәт<br>Без уйнарга яратабыз<br>Йомшак уенчык карау<br>Туп<br>Туган көн<br>Мияу кунакка килгән<br>Уенчыклар кибете | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 3. | Көз | Алтын көз<br>Көз килде<br>Аваз культурасы, Ө авазы<br>Куян үстергән кишер һәм помидор<br>Яшелчә бакчасында<br>«Шалкан» әкияте<br>Җиләк-җимеш бакчасында<br>Бакчада алмалар өлгерде<br>Уйный-уйный саныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4. | Гаилә | Өйдә кем яши?<br>Безнең гаилә<br>Качышлы уйныйбыз<br>Тату гаилә<br>Минем дуслар<br>Әйдәгез дуслашыйк<br>Минем туганнарым<br>Безнең гаилә<br>Әби күчтәнәче<br>Дустыңны сыйла<br>Сөт,чәй<br>Кунакка барабыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 5. | Кыш | Кар ява<br>Алсуны урамга киендерәбез<br>А.Алиш «Куян кызы»<br>«Чанада шуабыз» рәсемен карау<br>Кышкы уеннар<br>«Куяннар» уенын өйрәнү | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6. | Яңа ел бәйрәме | Тиздән чыршы бәйрәме<br>Б.Рәхмәтнең «Кыш бабай» шигырен ятлау<br>Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>Без бәйрәмгә әзерләнәбез<br>Бәйрәм концерты<br>Яңа ел бәйрәме | 1<br>1<br><br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7. | Минем йортым, минем | Минем шәһәрем | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шәһәрем | Мин «КамАЗ» оныгы<br>«Әлли-бәлли итәргә...«Бишек җыры»<br>Безнең урам<br>Алсуның яңа өе<br>Алсуда кунакта | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8. | Безнең авылда | Безнең авылда<br>Зурлар һәм кечкенәләр<br>«Кем нәрсә ярата?» татар халык әкиятен сөйләү<br>«Песи һәм песи балалары» рәсемен карау<br>Ж.Тәрҗемановның «Үзен бик чиста йөртә» шигырен уку<br>«Кем МИЯУ дип әйтте?»<br>Йорт кошлары<br>Р.Батулланың «Елак әтәч» әсәрен уку<br>Без уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 9. | Ватанны саклаучылар көне | Зур гаилә<br>Безнең әтиләр һәм абыйлар<br>Бабайга кунакка барабыз<br>Ватанны саклаучылар көне<br>Очучылар<br>З.Туфайлованың «Шофёр булам» шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. | 8нче март | Минем әнием<br>Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!<br>Без әнигә булышабыз<br>Әбигә кунакка барабыз<br>Мин әнинең ярдәмчесе<br>Азат кунак чакыра | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 11. | Кыргый хайваннар | Урманда<br>Аю белән куян<br>«Өч аю» әкияте | 1<br>1<br>1 |
| 12. | Әкияттә кунакта | «Теремкәй» рус халык әкиятен сөйләү<br>Кыргый хайваннар<br>«Төлке, куян һәм әтәч» әкиятен сәхнәләштерү | 1<br>1<br>1 |
| 13. | Яз | Урамда яз<br>Яз җитте<br>Яз җыры<br>«Кояш чык,чык,...»<br>Язгы күренешләр<br>Ак аю кунакка килгән<br>Кошлар<br>Х.Вахитның «Уңган сыерчык» шигырен уку<br>Без уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 14. | Бәйрәмнәр | Бәйрәмгә барабыз<br>«Балалар бакчасында бәйрәм» дигән рәсем карау<br>«Урманда зур концерт» - анимацион сюжет карау | 1<br>1<br>1 |
| 15. | Җәй | Автобуста сәяхәт<br>Ж.Тәрҗемановның «Кикрикүк» шигырен уку<br>Мультфильмда кунакта<br>М.Мазуновның «Кәҗә» шигырен уку<br>«Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре» рәсемен карау<br>Чәчәкләр-тормыш яме<br>Матур җәй, кил безгә<br>Мин җәйне яратам<br>«Карга» эндәшен уку<br>Саф һавада<br>Экология сукмагы буенча сәяхәт | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Без уйныйбыз | 1 |
| | | | 105сәгать |

**«Туган телдә сөйләшәбез»**
**Комплекслы тематик план. Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)**

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Без балалар бакчасында | Танышу<br>Без балалар бакчасында | 1<br>1 |
| | | Әкиятләр иленә сәяхәт | 1 |
| 2. | Мин - дөньяның бер кешесе | Әти, әни һәм мин<br>«Гаилә» рәсемен карау<br>Г. Тукай «Безнең гаилә» шигырен уку<br>Г. Тукай «Безнең гаилә» шигырен ятлау<br>Гаилә<br>Мин һәм кешеләр | 1<br>1<br>1<br>1<br>2<br>2 |
| | | «Көз һәм балалар» җыры<br>Анимацион сюжет «Шалкан әкияте буенча»<br>Әйдәгез, дуслашыйк. | 2<br>1<br>1 |
| 3. | Ю | Б.Рәхмәт «Су» шигырен уку<br>Б.Рәхмәт «Су» шигырен ятлау | 1<br>1 |
| | | Качышлы уйныйбыз | 1 |
| 4. | Көз | Көз килде<br>«Көз» рәсемен карау | 1<br>1 |
| | | Качышлы уйныйбыз | 1 |
| 5. | Куян күчтәнәчләре | Куян күчтәнәчләре | 2 |
| | | «Шалкан» әкияте | 1 |
| 6. | Көз күчтәнәчләре | Җимешләр<br>Р.Батулла «Аю Әппәс» әкиятен сөйләү | 1<br>1 |
| | | Әйдәгез, уйныйбыз | 1 |
| 7. | Табын янында. | Ашамлыклар<br>Әбине сыйла<br>Сыйла<br>Без кибеткә барабыз, ашамлыклар алабыз<br>Аш бүлмәсе | 2<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | Безнең кунаклар<br>Дустыңны сыйла<br>Кунак сыйлау | 1<br>1<br>1 |
| 8. | Татар халык ашлары | Татар халык ашлары | 2 |
| | | Азат кунак чакыра | 1 |
| 9. | Безнең уенчыклар | Безнең уенчыклар<br>Әйдәгез уйныйбыз<br>Уенчыклар белән уйныйбыз<br>Уенчыклар кибете<br>Без уйнарга яратабыз<br>Уйныйбыз<br>Минем яраткан уенчыкларым | 3<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | Уенчыклар<br>Паркка сәяхәт<br>Алсуның туган көне<br>Яңа ел килә<br>Ә.Баринның «Кыш» шигырен уку | 2<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. | Кыш | Җәнлекләр кышка әзерләнә<br>Җәнлекләр кышкы урманда<br>А.Алиш «Куян кызы»<br>Кыргый хайваннар | 1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хәйдәрнең «Керпе туны» әкиятен уку<br>Ә.Бариның «Кыш» шигырен уку | 1<br>1 |
| | | Паркка сәяхәт<br>Уйныйбыз<br>Мияуга бүләк | 1<br>1<br>1 |
| 11. | Халык җәүһәрләре | Киемнәр | 2 |
| | | «Ни өчен киемнәр югалган» | 1 |
| 12. | Ватанны саклаучылар | Безнең Армия<br>Хәрби һөнәрләр<br>Очучылар<br>Без солдатлар<br>К. Булатованың «Солдатлар» шигырен уку<br>Иң яхшы әти | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | Уенчыклар үпкәләгән<br>«Күңелле уеннар»<br>Уенчыклар юабыз | 1<br>1<br>1 |
| 13. | 8 март | Әнием турында сөйлим<br>З.Туфайлованың «Әни сүзе» шигырен ятлау | 1<br>1 |
| | | Саннар | 2 |
| 14. | Яз | Кар Бабай язны эзли<br>Яз бүләкләре<br>Нур Гайсинның «Яз килә» шигырен уку<br>«Без язны яратабыз» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| | | Уйныйбыз да, саныйбыз да | 1 |
| 15. | Күчмә кошлар | Күчмә кошлар<br>Х.Вахитның «Уңган сыерчык» шигырен уку<br>Б. Рәхмәтнең «Яз» шигырен ятлау | 2 |
| | | Бергәләп өйрәник<br>«Акбай һәм Мияу маҗаралары» | 1<br>1 |
| 16. | Халык җәүһәрләре | Кунак чакырабыз | 2 |
| | | «Күңелле ял итәбез» | 1 |
| 17. | Апрель җитсә, исемеңне җырына куша тургай | Габдулла Тукай<br>Габдулла Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигырен уку<br>Габдулла Тукайның «Гали белән кәҗә» шигырен ятлау | 2<br>1<br>1 |
| | | Без татарча сөйләшәбез | 2 |
| 18. | Йорт хайваннары | Йорт хайваннары<br>К.Ушинскийның «Хайваннар бәхәсе» әсәре | 1<br>1 |
| | | Бу өйдә кем яши? | 1 |
| 19. | Минем дусларым | «Торна белән Төлке» әкиятен уку<br>«Без татарча сөйләшәбез»<br>Ж.Тәрҗемановның «Кикрикүк» шигырен уку<br>А.Алишның «Чукмар белән Тукмар» әкияте буенча әңгәмә | 2<br>1<br>1 |
| | | Без театр уйныйбыз<br>Уйныйбыз | 1<br>1 |
| 20. | Сабантуй бәйрәме | Сабантуйга әзерләнәбез<br>Күңелле Сабантуй | 1 |
| | | Сабантуй бәйрәме | 1 |
| | | | 104 сәгать |

**«Туган телдә сөйләшәбез»**
**Комплекслы тематик план. Зурлар төркеме (5-6 яшь)**

| | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | «Яхшы сүз-җан азыгы» | Танышу<br>Ягымлы сүзләр<br>Сыйла(катнаш эшчәнлек) | 1<br>1<br>1 |
| 2. | А. Алиш иҗаты | А.Алиш- балалар язучысы.<br>А.Алиш «Каз белән аккош» | 1<br>1 |
| | | «Чукмар белән Тукмар» (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 3. | Хуш киләсең, ямьле көз! | Җәйләр үтте, көзләр җитте.<br>Көзге табигать | 1<br>1 |
| | | «Шалкан» (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 4. | Көз күчтәнәчләре | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт<br>Сыйлыйбыз | 1<br>1 |
| | | «Баллы кишер» (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| | | Түтәлләрдә үсте яшелчә<br>Яшелчәләр кибете<br>Бар матур бакча | 1<br>1 |
| 5. | Мин яратам сине, Татарстан | Мин яратам сине, Татарстан<br>Туган җирем-Татарстан | 1<br>1 |
| | | «Уйный-уйный эшлибез» | 1 |
| | | Гүзәл туган ягыбыз<br>Туган ил кайдан башлана? | 1<br>1 |
| | | Мультфильм «Акбарс» | 1 |
| 6. | Төсләр дөньясы | Төсләр. Төсләр дөньясы | 1/1 |
| | | «Юл маҗаралары». | 1 |
| 7. | Кем эшләми, шул ашамый | Яшелчә салаты<br>Яшелчәләр юабыз. | 1<br>1 |
| | | «Кем эшләми, шул ашамый» | 1 |
| 8. | Җиләк-җимешләр | Җимешләр<br>Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>Җиләк-җимешләр | 1<br>1<br>1 |
| 9. | Минем гаиләм | Безнең гаилә<br>Әби, бабайларны хөрмәтлик. | 1<br>1 |
| | | «Аш бүлмәсе» | 1 |
| 10. | Табын янында | Савыт-саба кибетенә сәяхәт.<br>Савыт-саба.<br>Бергәләп өйрәнәбез.<br>Курчак Алиягә булыш<br>Чәй табыны | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | «Өч аю» . | 1 |
| 11. | Киемнәр дә безне бизиләр | Кием кешене бизи<br>Кием-салым кибетенә сәяхәт | 1<br>1 |
| | | «Киемнәр кибетендә» | 1 |
| 12. | Салкын кыш Кышкы уеннар | Салкын кыш<br>Кышкы уеннар | 1<br>2 |
| | | «Хат ташучы Кар бабай» | 1 |
| | | Без суыктан курыкмыйбыз.<br>Кыш | 1<br>1 |
| | | «Киемнәр кибетендә» | 1 |
| | | Кышкы уеннар | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Ел фасыллары | 1 |
| | | Куян кызы | 1 |
| 13. | Кунак булсаң-тыйнак<br>бул | Без ашыйбыз<br>Мин кунак яратам<br>Бергәләп өйрәнәбез | 1<br>1<br>1 |
| 14. | Киемнәр | Киенергә ярдәм ит<br>Милли киемнәр. | 1<br>1 |
| | | «Киемнәр кибетендә» | 1 |
| | | Киемнәр дә безне бизиләр.<br>Киемнәр дөняьсы | 1<br>1 |
| | | «Ни өчен киемнәр югалган» | 1 |
| 15. | Йорт җиһазлары | Матур әдәбият белән таныштыру. Өстәл<br>театры «Өч аю»<br>Өй җиһазлары кибете. | 1<br><br>1 |
| | | «Маша һәм өч аю» | 1 |
| 16. | Муса Җәлил безнең<br>күңелләрдә. | Муса Җәлил безнең күңелләрдә.<br>«Батырлыкта-матурлык» | 1<br>1 |
| | | «Шаян уенчыклар». | 1 |
| 17. | Кояш гомере телим<br>мин, әнием, сиңа | Без әни белән кибеткә бардык<br>Әниләр бәйрәме | 1<br>1 |
| | | «Өч кыз» | 1 |
| | | Әни кирәк<br>Әниемнең тәмле ашлары | 1<br>1 |
| | | «Туган көн» | 1 |
| 18. | Без язны яратабыз | Яз килә.<br>Яз килә, яз! | 1<br>1 |
| | | «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| | | Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>Нәүрүз – яз бәйрәме<br>Бар, юк | 1<br>1<br>1 |
| 19. | Безнең канатлы<br>дусларыбыз | Күчмә кошлар<br>Кошлар | 1<br>1 |
| | | «Алтын ай» кибете | 1 |
| 20. | Габдулла Тукай<br>иҗаты | Габдулла Тукай<br>Г. Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигырен уку. | 1<br>1 |
| | | Тукай әсәрләреннән төзелгән<br>мультфильмнардан өзекләр карау. | 1 |
| | | Г. Тукай «Безнең гаилә»<br>«Гаилә» рәсемен карау | 1<br>1 |
| | | Г. Тукай «Бала белән күбәләк» | 1 |
| 21. | Чисталыкта-<br>матурлык | Саулык-зур байлык<br>Шигырь уку: Ә.Ерикәй «Чисталык сөябез» | 1<br>1 |
| | | «Чисталыкта-матурлык» | 1 |
| 22. | Җиңү алып килде май | Сугыш ветераннары белән очрашу | 1 |
| 23. | Кунак көтәбез | «Винни – пух кунакка бара» | 1 |
| | | «Чебурашка» | 1 |
| 24. | Хәрәкәттә -бәрәкәт | Минем яраткан спорт төре.<br>Шигырь уку: В Хәйруллина «Туплар» | 1<br>1 |
| | | Арыслан баласы һәм ташбака ничек җыр<br>җырлаган | 1 |
| 25. | Чәчәкле җәй | Чәчәкләр-тормыш яме<br>Чәчәкле җәй. | 1<br>1 |
| | | Сабантуй бәйрәме | 1 |
| 26. | Күңелле Сабантуй | Күңелле Сабантуй уеннары<br>Сабан туена әзерлек | 1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Сабан туена әзерлек | 1 |
| | | | 102 |

**«Туган телдә сөйләшәбез»**
**Комплекслы тематик план. Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 – 7 яшь)**

| | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Әйдәгез, танышабыз! | Әйдәгез, танышабыз<br>Тәмле сүз – җан азыгы | 1<br>1 |
| | | «Мияу адашкан» | 1 |
| 2. | Тату гаилә | Минем өем<br>Тату гаилә<br>«Аю баласы дөнья белән таныша» | 1<br>1<br>1 |
| 3. | Абдулла Алиш иҗаты | А. Алиш иҗаты белән танышу.<br>А.Алиш «Сертотмас үрдәк» әкияте<br>«Батыр Мияу белән куркак Куянкай» | 1<br>1<br>1 |
| 4. | Алтын көз | Алтын көз<br>Көз җитте<br>«Шалкан» | 1<br>1<br>1 |
| 5. | Көзге байлык | Яшелчәләр<br>«Кем эшләми, шул ашамый» | 2<br>1 |
| 6. | Көз күчтәнәчләре | Җиләк – җимешләр<br>Көз күчтәнәчләре<br>«Без сыйланабыз» | 1<br>1<br>1 |
| 7. | Икмәк – яшәү терәге | «Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә»<br>Кунак чакырдык<br>«Юмарт аю» | 1<br>1<br>1 |
| 8. | Ашамлыклар | Ашамлыклар<br>Кунак көтәбез<br>«Кафега барабыз» | 1<br>1<br>1 |
| 9. | Савыт-саба | Савыт – саба | 2 |
| | | «Тәмле» кафесы ачабыз | 1 |
| 10. | Өй җиһазлары | Минем өем, өй җиһазлары | 1 |
| | | «Тәмле» кафесында | 1 |
| 11. | Милли киемнәр | Әбиемнең серле сандыгы<br>Кием кешене бизи<br>«Күңелле уеннар» | 1<br>1<br>1 |
| 12. | Минем туган җирем | Татарстан буйлап сәяхәт<br>Спорт бәйрәменә барабыз | 1<br>1 |
| | | «Көчлеләр, кыюлар, җитезләр» | 1 |
| 13. | Башкалам - Казан | Башкалам – Казан<br>«Туган илем – туган өем» | 1<br>1 |
| | | Әниләр бәйрәменә барабыз | 1 |
| 14. | Кыргый хайваннар | Кыргый хайваннар | 2 |
| | | «Циркта» | 1 |
| 15. | Ишек алдында | Йорт кошлары<br>Йорт хайваннары | 1<br>1 |
| | | «Төлке һәм каз» мультфильмы | 1 |
| 16. | Кыш килде | Кыш килде<br>Кыш | 1<br>1 |
| | | «Безнең дуслар» | 1 |
| 17. | Кышкы уеннар | Кышкы уеннар<br>Яңа ел бәйрәме | 1<br>1 |
| | | «Кар малай» мультфильмы | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18. | Кыш<br>Кышкы уеннар | Кыш. Кышкы уеннар | 2 |
| | | «Шаян кошлар» | 1 |
| 19. | Кышлаучы кошлар | Кышлаучы кошлар<br>Кошлар кафесы<br>Кошларга ярдәм итик | 2<br>1<br>1 |
| | | «Әйдә, бие! » | 1 |
| | | «Урманда зур концерт» | 1 |
| 20. | Киемнәр | Киемнәр<br>Кышкы киемнәр | 1<br>1 |
| | | «Акбай туган көнгә барырга әзерләнә» | 1 |
| 21. | Муса Җәлил | Муса Җәлил | 2 |
| | | «Мияуның туган көне” | 1 |
| 22. | И туган тел,<br>и матур тел | Бөтендөнья телләр көне<br>И туган тел, и матур тел... | 1<br>1 |
| | | «Урман китапханәсендә» | 1 |
| 23. | Безнең шәһәр | Безнең шәһәр | 2 |
| | | «Уйный – уйный укыйбыз» | 1 |
| 24. | Ямьле яз | Ямьле яз | 2 |
| | | «Урман мәктәбендә» | 1 |
| 25. | Әкияттә кунакта | Әкияттә кунакта<br>«Хуш киләсең, Нәүрүз!» | 1<br>1 |
| | | «Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү | 1 |
| 26. | Күчмә кошлар | Күчмә кошлар | 2 |
| | | «Кем нәрсә ярата?» | 1 |
| 27. | Белем иленә сәяхәт | Белем иленә сәяхәт<br>Серле чәчәк<br>Уку бүлмәсе | 2<br>1<br>1 |
| | | «Уйный – уйный укыйбыз» | 1 |
| 28. | Мәктәп | Без мәктәпкә барабыз | 2 |
| | | «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» | 1 |
| | | «Юл маҗаралары» | 1 |
| 29. | Урман-безнең<br>байлыгыбыз | Урманда<br>Нәрсә ул «Кызыл китап?» | 1<br>1 |
| | | Габдулла Тукай | 1 |
| 30. | Габдулла Тукай | Г. Тукай әкиятләренә сәяхәт<br>Без – Тукай оныклары | 1<br>1 |
| | | Г. Тукай «Шүрәле» | 1 |
| 31. | Әкияттә кунакта | «Эш беткәч, уйнарга ярый»<br>«Алтын бөртекләр»<br>«Агачлар да авырый» | 1<br>1<br>1 |
| 32. | Белем иленә сәяхәт | Могҗизалар кыры<br>Белем иленә сәяхәт | 1<br>1 |
| 33. | Без уйнарга яратабыз | Казанга спорт бәйрәменә барабыз<br>Без уйнарга яратабыз<br>Сюжетлы – рольле уеннар | 1<br>2<br>1 |
| 34. | Җиңү бәйрәме | Алар безгә җиңү бүләк итте<br>Җиңү бәйрәме | 1<br>1 |
| 35. | Хуш бакчам, исәнме<br>мәктәп | Кабатлау.<br>«Хуш бакчам, исәнме мәктәп» | 1<br>1 |
| | | | 108 сәгать |

- ➢ **УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ (4-5 яшь)** . «Минем өем» проекты

**БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БУРЫЧЛАРЫ:**

- ✓ Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклар хисабына сүз байлыгын арттыру.
- ✓ Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү.
- ✓ Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.
- ✓ Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү.
- ✓ Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2 - 3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

**БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ:**

«Минем өем» проекты якынча 62 сүз тәшкил итә. Проект 4 теманы үз эченә ала: «Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар». Тәрбиячеләр алдында түбәндәге бурычлар тора:

✓ Проектның темалары буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

✓ Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

✓ Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү.

✓ Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру.

✓ Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.

✓ Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

-*Бу кем? – Бу әти.*

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*

✓ Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү. -*Туп нинди? – Кечкенә.*

-*Машина нинди? – Матур.*

✓ Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле). -*Бу нәрсә? – Бу туп.*

-*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*

✓ Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал). -Мә, куян. – Бир куян.*

✓ Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү. *Зур машина ал. Тәмле алма бир.*

✓ Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану. *Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.*

✓ Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче *(әйе, юк)* сүзләрне, шулай ук *(мин, син)* алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү *Син Коля? – Әйе. Син кыз? – Юк, мин малай.*

✓ Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ (Ирешелгән нәтиҗәләр)**

- ✓ Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
- ✓ Татар телендә сөйләшү теләге бар.

- ✓ Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.
- ✓ Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.
- ✓ Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.
- ✓ Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.
- ✓ Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.
- ✓ Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә.
- ✓ Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.
- ✓ Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә.
- ✓ Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана.
- ✓ Куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә
- ✓ Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.
- ✓ Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

**ТӘРБИЯЧЕ ҺӘМ АТА – АНАЛАР БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ КИРӘКЛЕ НӘТИҖӘЛӘР ИРЕШҮ ӨЧЕН ТҮБӘНДӘГЕ КИМЧЕЛЕКЛӘРНЕ БЕТЕРЕРГӘ КИРӘК:**

1. Сүз байлыгы аз. Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
2. Сорауларны аңлый, җавап бирә алмый.
3. Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белми.

## ➢ ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ (5-6 яшь) «Уйный – уйный үсәбез» проекты

**БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БУРЫЧЛАРЫ:**
- ✓ Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй
- ✓ җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
- ✓ Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү.
- ✓ Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.
- ✓ Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә
- ✓ камилләштерү.
- ✓ Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

**БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ:**

«Уйный-уйный үсәбез» проекты якынча 45 сүз тәшкил итә һәм түбәндәге темаларны үз эченә ала: «Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр»

✓ Проектның темалары буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

✓ Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр,кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*

✓ Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.

✓ Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

✓ Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*

✓ Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру. - *Бу кызыл тәлинкә.*

✓ «Минем өем» проектытбуенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю,уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.

✓Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү

**БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ (Ирешелгән нәтиҗәләр) .**

✓ «Уйный-уйный үсәбез» проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар»,

«Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр») буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

- ✓ Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.
- ✓ Санау күнекмәләрен сөйләмдә актив куллана белә.
- ✓ Куелган сорауларга: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? (юа) соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.
- ✓ Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.
- ✓ Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.
- ✓ Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.
- ✓ Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

**ТӘРБИЯЧЕ ҺӘМ АТА – АНАЛАР БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ КИРӘКЛЕ НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШҮ ӨЧЕН ТҮБӘНДӘГЕ КИМЧЕЛЕКЛӘРНЕ БЕТЕРЕРГӘ КИРӘК:**

1. Сүз байлыгы аз. Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
2. Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белми.
3. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алмый.

## ➢ **МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ (6-7 яшь)**. «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты

**БЕЛЕМ БИРУ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БУРЫЧЛАРЫ:**

1. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
2. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
4. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

**БЕЛЕМ БИРУ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ:**

«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты якынча 60 сүз тәшкил итә һәм түбәндәге темаларны үз эченә ала: «Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр» «Танышу», “Тату гаилә», «Дусларны сыйлыйбыз», «Кунак килде», «Кафега барабыз», «Күңелле уеннар», «Без циркта», «Безнең дуслар», «Мәктәп», «Чана шуабыз», «Без биибез», «Күңелле сәяхәт», «Без әкият яратабыз»

- ✓ Алда әйтеп үтелгән темалар буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
- ✓ Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, нишлисең, ашый – ашыйм, эчә - эчәм, уйный – уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер – сикерәм, сикерә, төлке, йөгер – йөгерәм, йөгерә, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа – шуам, бие – бии, биим, ак, кара, җырла – җырлыйм, җырлый, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*
- ✓ Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
- ✓ Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, уен ситуацияләрендә, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**БЕЛЕМ БИРУ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ (Ирешелгән нәтиҗәләр)**

«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты темаларны «Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр» «Танышу», «Тату гаилә», «Дусларны сыйлыйбыз»,

«Кунак килде», «Кафега барабыз», «Күңелле уеннар», «Без циркта», «Безнең дуслар», «Мәктәп», «Чана шуабыз», «Без биибез», «Күңелле сәяхәт», «Без әкият яратабыз» буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

- ✓ Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бай.
- ✓ Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.
- ✓ Боерык фигыльләрне ( кил монда, утыр, аша, эч, йокла, уйна, ю, сикер, җырла, бие, йөгер, бас...) урынлы куллана.
- ✓ Проект буенча җырлар, бармак уеннары, әйлән – әйлән уеннарын, шигырьләр белә.

**ТӘРБИЯЧЕ ҺӘМ АТА – АНАЛАР БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ КИРӘКЛЕ НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШҮ ӨЧЕН ТҮБӘНДӘГЕ КИМЧЕЛЕКЛӘРНЕ БЕТЕРЕРГӘ КИРӘК:**

1. Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы аз.
2. Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана алмый.
3. «Бу кем?», «Бу нәрсә?», «Нәрсә кирәк?», «Нинди?», «Ничә?», «Нишли?», «Син нишлисең?», «Кая барасың?», «Нәрсә бар?» аңламый, сорауларын мөстәкыйль рәвештә куя белми. Фигыльләрне урынлы куллана белми.

**ЭШ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ:**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Шуларны истә тотып түбәндәге эш төрләрен һәм формаларын кулланырга кирәк:Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.

- ✓ Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
- ✓ Дидактик уеннар, сүзле уеннар. Сюжетлы – рольле уеннар (иҗади уеннар)/ Әйлән – бәйлән, җырлы – биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
- ✓ Театральләштерү, сәхнәләштерү (өстәл өсте театры, бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти – әниләргә, башка төркем балаларына).
- ✓ Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, «Командир» уены, әйлән – бәйлән уен, зарядка уеннары. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
- ✓ Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
- ✓ Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
- ✓ Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
- ✓ Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау. Интерактив уеннар.

## ИННОВАЦИОН ЭШ.

Яшәешне электрон технологияләре чолгап алган бу заманда балаларга белем бирү процессы да үзгәрешсез кала алмый. Берничә дистә телеканалдан мультфильмнар карауга, компьютер уеннарына күнегеп беткән балалар өчен, аларның кабул итү мөмкинлекләренә туры килгән яңа чаралар уйлап табу - заман таләбе.

Рус балаларына татар теле өйрәтүдә интерактив такта балаларга белем бирү өчен иң мөһим интерактив инструментларның берсе булып тора. Аның ярдәмендә эшчәнлекне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештырырга мөмкин. Интерактив такта төрле мультимедия ресурсларда бирелгән мәгълүматларны файдаланырга, комментарийлар кулланырга, эшчәнлекне өстәмә мәгълүматлар белән баетырга мөмкинлек бирә. Уенчыклар, рәсемнәр кулланып яки ковролинда аңлатып булмаган материалны нәкъ менә интерактив такта ярдәмендә бирергә була. Мондый тактада булган һәрбер объектны күчереп йөртергә, тиз арада яңа рәсемнәр ясарга, аларга төсләр бирергә, үзгәртергә һәм бетерергә, белем бирүдә ике яклы диалогка ирешергә (интерактив такта- бала), интернеттагы ресурслардан файдаланырга мөмкин (видео материал карау).

Баланың күз алдында барган динамик үзгәрешләр: экрандагы хәрәкәт, төс, тавыш информация бирүне аңлаешлы һәм кызыклы , ә балаларны игътибарлы булырга мәҗбүр итә, шуңа күрә тема барлык балаларга да җиткерелә дип уйларга нигез бар.

Тәҗрибәләр күрсәткәнчә, интерактив такта куллану балаларның өйрәнә торган тема белән кызыксыну дәрәҗәсе артуына китерә һәм телне өйрәнү теләкләрен дә арттыра.

«Информацион- коммуникатив технологияләрне мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып-белү эшчәнлекләрен һәм телен үстерүдә куллану» программасын тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган.

Барлык педагоглар да Microsoft Power Point программаларында меток эшкәртмәләр ясау һәм компьютерны өйрәнү буенча курслар үттеләр. Санитар- гигиеник таләпләргә туры килгән махсус җиһазландырылган кабинет бар.

**ТАТАР ТЕЛЕН ҮЗЛӘШТЕРҮ ДӘРӘҖӘЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ.**

**«МИНЕМ ӨЕМ»**

проекты буенча уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

| № | БАЛАЛАРНЫҢ ИСЕМ ФАМИЛИЯСЕ | БИРЕМНӘР | | | | | НӘТИҖӘ | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Минем өем» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | Баллар / Дәрәҗә | |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә - 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә - 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә -1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

## Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.

**I. «МИНЕМ ӨЕМ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ӨЙРӘНГӘН ЛЕКСИКАНЫ СӨЙЛМӘМДӘ КУЛЛАНУ**

(Темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)

**1. Дидактик уен.** «**Бу кем?**» (Івариант) (Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)
Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? («Әни»...).
**2. Дидиктик уен** «**Кем юк?**» (II вариант) (Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)
Уен эчтәлеге: Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: «Кем юк?» («Әби»...)
Уенны интерактив тактада, проекцион техника экранында, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була.
**3. Дидактик уен «Кәрзиндә нәрсә бар?»** (Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)
Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: «Бу нәрсә?» («Алма»...)
**4. Дидактик уен «Нәрсә юк?»** (Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: «Нәрсә юк?». Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. («Алма"...)Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.
**5. Дидактик уен «Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт»** (Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай, куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).
Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күрсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.
**6. Дидактик уен «Исемен әйтсәң бирәм»** (Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай, куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).
Уен эчтәлеге: Өстәлдә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны (рәсемне) күрсәтә, сорый: «Бу нәрсә?" - «Алма».. ; «Бу кем?» - «Әти»... Бала дөрес җавап бирсә, аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.
**7. Дидактик уен «Серле янчык»** (Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)
Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.
**8. Дидактик уен «Әйе-юк»**
Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: «Бу нәрсә?» - «Аю»; «Бу аю?»- «Әйе, аю»; «Бу куян? »- «Юк, песи».

***Югары балл** (2,7-3) — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.*
***Уртача балл** (2-2,6) - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.*
***Уртачадан түбән балл** (1-1,9) - аңлый, русча җавап бирә.*

**II. ЯГЫМЛЫ СҮЗЛӘР КУЛЛАНУ («ИСӘНМЕ», «ИСӘНМЕСЕЗ», «САУ БУЛ» , «САУБУЛЫГЫЗ», «РӘХМӘТ», «ХӘЛЛӘР НИЧЕК?»)**

**1. Ситуатив күнегүләр.**
а) «Куян аюга кунакка килә». Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?) - «Исәнме аю».
б) «Куян аюда кунакта булды». Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) - «Сау бул, аю».
в) «Акбайга («Мияуга», «Курчакка», «Дустыңа») уенчык бүләк ит».
**2. Уен ситуациясе «Кунак сыйлау».** Акбайда (Мияуда) кунакта.
Уен эчтәлеге: Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән «сыйлый». Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.
**3. Уен ситуациясе «Дустыңны сыйла».** Балаларны парлаштырып бер-берсе белән исәнләшеп, хәлләрен сорап, сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.

***Югары балл** (2,7-3) - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.*
***Уртача балл** (2-2.6) - тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.*
***Уртачадан түбән** (1-1,9) - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.*

**III. БОЕРЫКНЫ АҢЛАП ҮТӘҮ ҺӘМ КУЛЛАНА БЕЛҮ (КИЛ, УТЫР, Ю, АША, ЭЧ, УЙНА)**

**1. Сүзле уен «Шаян уенчыклар»**
(Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерү өчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык «ашый» башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).
**2. Сүзле уен «Мин әйтәм - син эшлә» («Командир»)**
Бала сүзне тыңлый, боерыкны үти.

***Югары дәрәҗә** (2,7-3) - бала боерыкны аңлап, дөрес үти.*
***Уртача дәрәҗә** (2-2,6) - ялгыша.*
***Уртачадан түбән дәрәҗә** (1-1,9) - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.*

**IV. ТИРӘ – ЮНДӘГЕ ПРЕДМЕТЛАРНЫҢ СЫЙФАТ БИЛГЕЛӘРЕН, КҮЛӘМЕН АЧЫКЛАУЧЫ(БЕЛДЕРҮЧЕ) СҮЗЛӘРНЕ АҢЛАП СӨЙЛӘМДӘ КУЛЛАНУ.**

**1. Дидактик уен «Уенчык нинди?»** (Лексика: зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).
Уен эчтәлеге: Уенчыклар күрсәтелә. Тәрбияченең «Нинди?» соравына бала уенчыкны сыйфат билгесе белән атарга тиеш.
Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.
**2. Дидактик уен«Тап, күрсәт һәм әйт».** (Лексика: чиста, пычрак).
Уен эчтәлеге: Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә. («Чиста туп», «Пычрак аю»..).
**3. Дидактик уен «Курчакка бүләк».** (Лексика: зур, кечкенә).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче зур курчакка - зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша. «Мә, зур туп », «Мә, кечкенә туп»
**4. Дидактик уен «Дөрес сана»**
Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. «Ничә малай? », «Ничә кыз?».
**5. Дидактик уен «Ничә?».**
Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була. - Ничә туп? - Биш туп.
**6. Сюжетлы-рольле уен: «Сыйлыйм»** (Лексика: тәмле)
- Оля, мә ипи, аша. Ипи тәмле(ме)? - Әйе, ипи тәмле.

***Югары дәрәҗә*** *(2,7-3)- әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөрес әйтә.*
***Уртача дәрәҗә*** *(2-2,6) - 1-2 билгесен әйтә.*
***Уртачадан түбән дәрәҗә*** *(1-1,9) - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.*

**V. АРАЛАША БЕЛҮ**
**(**ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау).

**1. Уен ситуациясе «Кунак каршылыйбыз»** ***К нам идут гости.***
Спроси. «Кто там?». «Кем анда?» Мин әби (бабай).
Позови бабушку (дедушку). -Әби (бабай) кил монда.
Поздоровайся с бабушкой (дедушкой) - Исәнме,әби (бабай).
Спроси у бабушки (дедушки) «Как дела?»- Әби (бабай) хәлләр ничек?- Әйбәт, рәхмәт.
Предложи бабушке (дедушке) сесть. - Әби (бабай) утыр.
Предложи бабушке (дедушке) пить чай. - Мә, чәй, эч.
Скажи: «До свидания!» Сау бул, әби! (бабай).
**2. Уен ситуациясе «Әйдәгез танышабыз»**
Уен эчтәлеге: «Син кем?» соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.
***К нам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться:***
- Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? - Мин Оля (Коля).
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? - Юк, мин малай (әйе, мин кыз).
**3. Балага «кунак» белән исәнләшергә, хәлен сорарга, чакырып утыртырга, сыйларга («аша, эч») һәм саубуллашырга тәкъдим ителә.**
*Эш дәфтәрендәге 3 нче биремне кулланып була.*
**4. Уен ситуациясе «Кунакларны сыйла»** ***Угости Акбай хлебом, Мияу молоком***.
-Мә, Акбай ипи, аша. - Рәхмәт. -Мә, Мияу сөт, эч. - Рәхмәт.
*Эш дәфтәрендәге 16 нчы биремне кулланып була.*
**5. Уен ситуациясе «Бер - береңне сыйла»** *(Ашамлык муляжлары кулланып)*
«***Угости яблоком***». - Мә, алма, аша.- Рәхмәт.
«***Спроси, яблоко вкусное?***» - Алма тәмле?- Әйе, тәмле.
*Эш дәфтәрендәге 6 нчы биремне кулланып була.*

**6. Уен ситуациясе «Уенчыклар илендә».** ***Ты пришел в магазин игрушек. Попроси игрушку, которая тебе нравится.*** -Куян бир (әле).- Рәхмәт.
***Предложи поиграть с игрушкой.*** - Мә, туп, уйна. - Рәхмәт.
***Позови друга, предложи помыть игрушку.*** -Коля, кил монда.- Мә, туп, ю.

**6. Поменяйтесь игрушками. Попроси у друга игрушку, предложи ему свою .**
- Коля, туп бир - Мә, туп. - Рәхмәт.

***Югары дәрәҗә*** *(2,7-3) - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.*
***Уртача дәрәҗә*** *(2-2,6) - тәрбияче ярдәмендә аралаша.*
***Уртачадан түбән дәрәҗә*** *(1-1,9) - аңлый, русча җавап бирә*

**«УЙНЫЙ – УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ»**
проекты буенча уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

| № | БАЛАЛАРНЫҢ ИСЕМ ФАМИЛИЯСЕ | БИРЕМНӘР | | | | | НӘТИҖӘ | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Уйный - уйный үсәбез» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану («Исәнме», «Исәнмесез», «Сау бул» , «Сау булыгыз», «Рәхмәт»,) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | Баллар | Дәрәҗә |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә - 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә - 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә - 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

## Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.

**I. «УЙНЫЙ – УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ӨЙРӘНГӘН ЛЕКСИКАНЫ СӨЙЛМӘМДӘ КУЛЛАНУ** (Темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)

**1. Дидактик уен «Бу нәрсә?»** (Лексика: аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: - Бу нәрсә? – Аш (Бу аш).

**2. Дидактик уен «Кәрзиндә нәрсә бар?»**
(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: - Нәрсә бар? – Кәбестә.

**3. Дидактик уен «Нәрсә юк?»** (Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя. Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш.
- Нәрсә юк? – Кишер юк. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

**4. Дидактик уен «Дөресен әйт»** (Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, карават).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый һәм күрсәтә.

***Югары балл (2,7-3)*** *— сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә, куелган сорауларга җавап бирә.*
***Уртача балл (2-2,6)*** *- сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.*
***Уртачадан түбән*** балл (1-1,9) - аңлый, русча җавап бирә.

**II. ЯГЫМЛЫ СҮЗЛӘР КУЛЛАНУ («ИСӘНМЕ», «ИСӘНМЕСЕЗ», «САУ БУЛ» , «САУБУЛЫГЫЗ», «РӘХМӘТ», «ХӘЛЛӘР НИЧЕК?»)**

**Ситуатив күнегүләр** :

- Поздоровайся с Акбаем.
- Попрощайся с Акбаем.
- Спроси как дела у Акбая.
- Поздоровайся с воспитателем, Мияу и Акбай.
- Скажи спасибо Акбаю.
- Попрощайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

***Югары балл (2,7-3)*** *— бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.*
***Уртача балл (2-2,6)*** *– уен ситуацияләрен тәрбияче ярдәмендә төзи.*
***Уртачадан түбән балл*** *(1-1,9)* – аңлый, җавап бирә алмый.

**III. БОЕРЫК БИРӘ БЕЛҮ. (кил, утыр, йокла, уйна, ю, аша, эч, ки, сал).**

**«КОМАНДИР» УЕНЫ** (Лексика: кил, утыр, йокла, ю, аша, эч, уйна, ки, сал).
Уен эчтәлеге: Балаларның боерыкларны бирә белү күнекмәләрен тикшерү. Балалар бер-берсенә боерык бирәләр. Саша, аша! – Саша ашау хәрәкәтләре күрсәтә. Алга таба Саша үзе башка балага боерык бирә һәм шундый тәртиптә дәвам итеклә.

***Югары балл (2,7-3)*** *– 8-9 сүз.*
***Уртача балл (2-2.6)*** *– 5-6 сүз.*
***Уртачадан түбән (1-1,9)***– 1-2 сүз.

**IV. УЕН СИТУАИЯЛӘРЕНДӘ ҮЗЛЕКТӘН СОРАУ КУЯ БЕЛҮ** (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

1. **Сюжетлы-рольле уен «Кибет»** (Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).
Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла. Өч төп сорауны куя белүләре тикшерелә. Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары рәсемнәре кулланып үткәрелә.
2. **Дидактик уен «Нинди?»** (Лексика: нинди? кызыл, сары, яшел, зәңгәр).
Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.
Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сорауга аңлап җавап бирү һәм ул сорауларны үзлектән куя белү.

3. **Дидактик уен «Дөресен әйт. Ничә?»**
Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

4. **Дидактик уен «Дөрес сана»**
Тәрбияче уенчыклар, муляжлар, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне санарга тәкъдим итә. Балалар бер-берсенә «Ничә...?» соравын куялар һәм җавап бирәләр. Шулай ук, сорауны тәрбияче үзе дә бирә ала. «Ничә...?»
***Югары балл (2,7-3)*** *– диалогта 3 сорауны да аңлап куллана.*
***Уртача балл (2-2.6)*** *– диалогта 2 сорауны аңлап куллана.*
***Уртачадан түбән (1-1,9)***– диалогта 1 сорауны аңлап куллана.

**V. АРАЛАША БЕЛҮ (**ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау

**1. Уен ситуациясе «Әйдәгез танышабыз»**

**«**Син кем?**»** соравына аңлап җавап бирүләре билгеләнә.

К вам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться:

- Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? - Мин Оля яки Коля.
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? - Юк, мин малай.

**2. Уен ситуациясе «Кунак каршылыйбыз»**

***К нам идут гости.***

- ✓ ***Спроси. «Кто там?»*** - Кем анда? - Мин Акбай.
  ***Позови Акбая.*** - Акбай, кил монда.
- ✓ ***У Акбая сегодня день рождение. Подари свою игрушку:***
  -Акбай, мә кызыл туп. - Рәхмәт.
- ✓ ***Угости гостей супом или кашей.***
  - Мә, аш (ботка) (аша).
- ✓ ***Что бы сьесть угощение попроси ложку.***
  - Кашык бир. - Нинди кашык? - Зур, матур, зәңгәр кашык. - Рәхмәт.

**3. Уен ситуациясе «Кибеттә»**

Бала белән бала аралашуы тикшерелә.

– Исәнме! – Исәнме!
– Хәлләр ничек? – Әйбәт, рәхмәт.
– Зур аю, чиста аю, матур аю.
– Мә, ике аю. – Рәхмәт.

– Хәлләр ничек? – Әйбәт, рәхмәт.
– Аю бир (әле). – Нинди аю?
– Ничә? – Ике аю.
– Сау бул. – Сау бул.

***Югары балл (2,7-3)** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.*

***Уртача балл (2-2,6)** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.*

***Уртачадан түбән (1-1,9)*** – аңлый, русча җавап бирә.

**«БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР»**

уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү**.**

<table>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2">БАЛАЛАРНЫҢ ИСЕМ ФАМИЛИЯСЕ</th><th colspan="5">БИРЕМНӘР</th><th colspan="2">НӘТИҖӘ</th></tr>
<tr><td rowspan="2">«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)</td><td rowspan="2">Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, “хәерле көн”, “хәлләр ничек?”, “әйбәт”)</td><td rowspan="2">Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла)</td><td rowspan="2">Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)</td><td rowspan="2">Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау)</td><td colspan="2">Баллар / Дәрәҗә</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1.</td><td>Коля</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>2.</td><td>Оля</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><th colspan="9">Нәтиҗәләрне билгеләү</th></tr>
<tr><td colspan="4">Югары дәрәҗә - 2,7 дән 3 кә кадәр</td><td colspan="5">Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Уртача дәрәҗә - 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә - 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

## Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.

**I. «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР, МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ӨЙРӘНГӘН ЛЕКСИКАНЫ СӨЙЛМӘМДӘ КУЛЛАНУ** (Темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)

**1. Дидактик уен «Бу нәрсә?»**
(Лексика: тычкан, бүре, төлке, керпе, тавык, әтәч, үрдәк).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? – Бүре (Бу бүре).

**2. Дидактик уен «Дөресен әйт. Портфельдә нәрсә бар?»**
(Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, карандаш һ.б.).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче портфельдән рәсемнәр яки предмет алып күрсәтә, исемен сорый: - Портфельдә нәрсә бар?- Дәфтәр бар.

**3. Дидактик уен «Дөресен әйт. Портфельдә нәрсә юк?»**
(Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, карандаш һ.б.).
Уен эчтәлеге: Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

**4. Дидактик уен «Дөресен әйт»**
(Лексика: чәк- чәк, өчпочмак, бәрәңге, аш, ботка).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый.

***Югары балл (2,7-3)*** *— 10-12 сүз.*
***Уртача балл (2-2,6)*** *– 7-9 сүз.*
***Уртачадан түбән балл (1-1,9)*** *– 1-6 сүз.*

**II. ЯГЫМЛЫ СҮЗЛӘР КУЛЛАНУ** («ИСӘНМЕ», «ИСӘНМЕСЕЗ», «САУ БУЛ» , «САУБУЛЫГЫЗ», «РӘХМӘТ», «ХӘЛЛӘР НИЧЕК?». «ЗУР РӘХМӘТ», «ХӘЕРЛЕ КӨН», «ӘЙБӘТ»,)

**Ситуатив күнегүләр:**
Телефоннан сөйләшү. *(Эш дәфтәрендәге 1 нче бирем)*

***Югары балл (2,7-3)*** *— бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.*
***Уртача балл (2-2,6)*** *– тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.*
***Уртачадан түбән балл*** *(1-1,9) – аңлый, сорауларга җавапны русча бирә.*

**III. БОЕРЫК БИРӘ БЕЛҮ. (**кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).

**1. Дидактик уен: «Командир»** *(Эш дәфтәрендәге 9 нчы бирем)*
(Лексика: кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).
Уен эчтәлеге: Бер бала икенче балага боерык бирә. Мәсәлән:
– Коля, сикер! (Коля сикереп күрсәтә).
– Коля, син нишлисең? (Колядан сорый) – Мин сикерәм.
– Коля нишли? (Башка баладан сорый) –Коля сикерә.

***Югары балл*** *(2,7-3) — 11-13 сүз белән боерык бирә, син нишлисең, нишли сорауларын бирә белә.*
***Уртача балл*** *(2-2,6) – бары боерык бирә, сорауларны куя алмый.*
***Уртачадан түбән балл*** *(1-1,9) – 1-5 сүз белән боерык бирә, сорауларны русча әйтә.*

**IV. УЕН СИТУАИЯЛӘРЕНДӘ ҮЗЛЕКТӘН СОРАУ КУЯ БЕЛҮ** (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Нишлисең? (Син нишлисең?) Ничә яшь? (Сиңа ничә яшь?) Кая барасың?)

**1. Уен ситуацияләре:**
а) «Кибет» (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)
б) «Телефоннан сөйләшү» (Кая барасың? Нишлисең? (Син нишлисең?)
в) «Танышу» (Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Ничә яшь? (Сиңа ничә яшь?)

**2. Сюжетлы-рольле уен «Кибет»** (Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).
Уен эчтәлеге: Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куллана белүләре тикшерелә.Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары, йорт кошлары, уенчык рәсемнәре кулланып үткәрелә.

***3.* Дидактик уен «Дөресен әйт. Нинди?»** (Лексика: кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара).
Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.

**4. Дидактик уен «Дөрес сана»**
Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

***Югары балл (2,7-3)** – сорауларны аңлап куллана.*
***Уртача балл (2-2,6)** – аңлый, тәрбияче ярдәме белән куллана.*
***Уртачадан түбән (1-1,9)**– русча җавап бирә.*

**V. АРАЛАША БЕЛҮ** (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау,сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау)

**1. Уен ситуациясе «Әйдәгез танышабыз»**
– Исәнмесез. Син кем? - (Мин Оля яки Коля).
– Мин кыз. Син кыз? - (Юк, мин малай).
– Сиңа ничә яшь?- (6 (7) яшь).

**2. Уен ситуациясе «Телефоннан сөйләшү»**
Диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була.
– Исәнме. Хәлләр ничек? - Әйбәт.
– Нишлисең? - Мин уйныйм. Син нишлисең?
– Мин ашыйм (бииим, утырам, сикерәм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм, барам, шуам, рәсем ясыйм, укыйм).
– Нәрсә? - Алма ашыйм.
– Алма тәмле(ме)? - Әйе, алма тәмле.
– Сау бул.

**3. Уен ситуациясе «Кая барасың?»** (Лексика: мәктәп, кафе, цирк һ.б.)
– Исәнме! Хәлләр ничек? - Әйбәт, рәхмәт.
– Кая барасың? - Кафега барам.
– Кафеда нәрсә бар? - (ашамлыклар атарга мөмкин)
– Саша нишли? - Саша бәрәңге ашый.

**4. Ситуатив күнегү.**
**Спроси: что ты делаешь?** - Син нишлисең?
– Мин ашыйм (биим, утырам, сикерәм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм, барам, шуам, рәсем ясыйм, укыйм).

***Югары балл (2,7-3)** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.*
***Уртача балл (2-2,6)** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.*
***Уртачадан түбән (1-1,9)**–* аңлый, русча җавап бирә.

**КОРРЕКЦИОН ЭШ**

Ярты елга бер диагностика үткәрелгән саен, нәтиҗәләргә карап коррекцион эш үткәрелә. Бала белем дәрәҗәләренең нәтиҗәләренә карап сайлап алына.
Түбәндә татар балалары һәм рус балалары белән коррекцион эш үткәрү буенча таблицаларда биремнәр бирелгән.

**МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ. ТАТАР БАЛАЛАРЫ Б ЕЛӘН КОРРЕКЦИОН ЭШ**

И туган тел, и матур тел!!!

| № | БАЛА ИСЕМЕ, ФАМИЛИЯСЕ ТӨРКЕМ САНЫ | ТЕМА<br>ЭШ ТӨРЛӘРЕ<br>(УЕННАР, КҮНЕГҮЛӘР, БИРЕМНӘР) | ҮТКӘРҮ (АЙ) | КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛ |
|---|---|---|---|---|
| 1 | ____________<br>____________ | **Үзең турында сөйләү**<br>1. Ситуатив күнегү: «Танышу кичәсе»<br>2. Сүзле уен «Мин, корреспондент» | X | Серле чәчәк (чәчәк таҗлары) |
| 2 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Ягымлы сүзләр**<br>1. Дидактик уен: «Серле чәчәк»<br>2. Ситуатив күнегү «Белмәмештә кунакта»<br>3. Ситуатив күнегү «Дустыңны кунакка чакыр»<br>4. Үстерешле диалог: «Сыйла» | X | Серле чәчәк (чәчәк таҗлары) Ситуатив күнегү, үстерешле диалог өчен атрибутлар |
| 3 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Сүзләрне темалар буенча гомүмиләштерү**<br>1. Дидактик уен «Бер сүз белән әйт»<br>2. Дидактик уен «Әйтсәң, бирәм»<br>3. Дидактик уен «Нәрсә артык?» (Карточкалар)<br>4. Сюжетлы – рольле уен «Савыт – саба кибете» | XI | Серле тартма – карточкалар (уенчыклар, савыт-сабалар, яшелчә, киемнәр. |
| 4 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Сорауларга җавап бирү кем? нәрсә? нишли? нинди? (Төс, зурлык) ничә?**<br>1. Сүзле уен: «Бу кем? Нишли?» (Пиктограммалар)<br>2. Дидактик уен: «Дөрес сана», «Нәрсә, нинди?»<br>3. Хәрәкәтле уен: «Мәликә» | XI | Рәсемнәр, санау өчен, уенчыклар, хәрәкәтне белдерүче пиктограммалар |
| 5 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Ү, Ә, Ң, Җ, Һ, Ө авазларының әйтелешен тикшерү**<br>1. Дидактик уен: «Сүзләр чылбыры»<br>2. Авазлар артикуляциясен ныгыту өчен күнегүләр.<br>3. Әйлән – бәйлән уены: «Ашъяулыкны бизә»<br>4. Сюжетлы – рольле уен: «Мәктәп» | XII | Авазлы рәсемнәр Әйлән-бәйлән уены өчен төсле кулъяулыклар Уеннар өчен атрибутлар |
| 6 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Җөмләләрне тулыландыру (малай...укый, чәчәк...ясый. Әти ...юа, әни... тегә**<br>1. Дидактик уен: «Бәйләнешле сүзләр тап»<br>2. Сүзле уен: «Әйтеп бетер», «Киресен әйт»<br>3. Дидактик уен: «Уйла һәм җөмләне тәмамла»<br>4. Үстерешле уен: «Сорау – җавап» | XII | Төрле сюжетлы рәсемнәр (Мәкальләр, сынамышлар, табышмаклар) |
| 7 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Мәгънәләре буенча капма-каршы сүзләр (антонимнар)**<br>1. Сүзле уен: «Мин башлыйм – дәвам ит»<br>2. Дидактик уен: «Яхшы–начар», «Ярый–ярамый»<br>4. Хәрәкәтле уен: «Чылбыр»<br>5. Табышмак әйтеш: «Табышмак әйтәм, җавап тап»<br>6. Сюжетлы–рольле уен: «Мәктәп», «Кибет» | I | Табышмак җавапларын табу өчен ярдәмче уенчык, рәсемнәр |
| 8 | ____________<br>____________<br>____________<br>____________<br>____________ | **Хайваннарның балаларын әйтү (Бер. Күп)**<br>1. Схема белән эш: «Хайваннар турында сөйлә»<br>2. Дидактик уен: «Хайваннарның балаларын тап» («Әнисенә булыш»), «Авылда»<br>3. Дидактик уен: «Серле китап» (Нәрсә? Кайда | II | Урман һәм йорт хайваннарының рәсемнәре (зур, кечкенә) уенчыклар. Серле |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | яши?) | | китап |
| 9 | | **Картина белән эш «Язгы урман»**<br>1. Сүзле уен: «Мин урманга бардым, нәрсә күрдем?».<br>2. Дидактик уен: «Хикәяне дәвам ит», «Кайсы әкият рәсеме». (Схема - пиктограммалар ярдәмендә үткәререп була) | **III** | «Язгы урман» картинасы. Пиктограммалар. Әкиятләрдән иллюстрацияләр |
| 10 | | **Әдәбият һәм фольклор**<br>1. Сүзле уен «Мин башлыйм, син дәвам ит»<br>2. Дидактик уен: «Тәрҗемәче», «Без әкият яратабыз» (1, 2 биремнәр – картиналар белән эш. Балага рәсем күрсәтелә, әкият исеме сорала<br>4. Дидактик уен: «Урынын тап» (лото) | **IV** | Төрле сюжетлы рәсемнәр. Әкият иллюстрацияләре. Дидактик уен «Лото» |
| 11 | | **Ана телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**<br>Төрле дидактик, үстерешле, хәрәкәтле, сүзле уеннар.<br>Пиктограммалар белән эш.<br>Картина өстендә эш. | **V** | Алда күрсәтелгән күрсәтмә материаллар |

**ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ. ТАТАР БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН КОРРЕКЦИОН ЭШ**

И туган тел, и матур тел!!!

| № | БАЛА ИСЕМЕ, ФАМИЛИЯСЕ ТӨРКЕМ САНЫ | ТЕМА<br>ЭШ ТӨРЛӘРЕ<br>(УЕННАР, КҮНЕГҮЛӘР, БИРЕМНӘР) | ҮТКӘРҮ (АЙ) | КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛ |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | **Үзең турында сөйләү**<br>1. Ситуатив күнегү: «Танышу кичәсе» | **X** | Серле чәчәк (чәчәк таҗлары) |
| 2 | | **Ягымлы сүзләр**<br>1. Дидактик уен: «Серле чәчәк»<br>2. Ситуатив күнегү «Белмәмештә кунакта» | **X** | Серле чәчәк (чәчәк таҗлары) |
| 3 | | Сүзләрне темалар буенча гомүмиләштерү<br>1. Дидактик уен «Бер сүз белән әйт»<br>2. Дидактик уен «Посылкада нәрсәләр бар?»<br>3. Дидактик уен «Нәрсә артык?» | **XI** | Серле тартма (уенчык, савыт-сабалар, яшелчә, киемнәр һ.б.) |
| 4 | | **Сорауларга җавап бирү Кем? Нәрсә? Нишли? Нинди? Ничә?**<br>1. Дидактик уен: «Бу кем? Нишли?» (Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар белән эш) , «Дөрес сана», «Бу нәрсә? Нинди төстә?»<br>2. Хәрәкәтле уен: «Мәликә» | **XI** | Рәсемнәр, санау өчен таякчык, уенчыклар, төсле туплар, тограммалар |
| 5 | | **Ү, Ә, Ң, Җ, Һ, Ө авазларының әйтелешен тикшерү**<br>1. Дидактик уен: «Сүзләр чылбыры»<br>2. Авазлар артикуляциясен ныгыту өчен күнегүләр.<br>3. Әйлән – бәйлән уены: «Кулъяулыгым» | **XII** | Бирелгән авазлар кергән рәсем, уенчык Уен өчен төсле кулъяулыклар |
| 6 | | **Җөмләләрне тулыландыру (аю..ашый, туп..төстә)**<br>1. Дидактик уен: «Бәйләнешле сүзләр тап»<br>2. Дидактик уен: «Җөмләне дәвам ит»<br>3. Сүзле уен: «Киресен әйт» «Мәкальне әйтеп бетер»<br>4. Үстерешле уен: «Сорау – җавап» | **XII** | Төрле сюжетлы рәсемнәр |
| 7 | | **Мәгънәләре буенча капма-каршы сүзләр**<br>1. Дидактик уен: «Мин башлыйм – дәвам ит»<br>2. Дидактик уен: «Яхшы – начар»<br>3. Хәрәкәтле уен: «Чылбыр»<br>4. Табышмак әйтеш: «Табышмак әйтәм, җаваб тап» | **I** | Табышмак җавапларын табу өчен ярдәмче уенчык, рәсемнәр |
| 8 | | **Хайваннарның балаларын әйтү (Бер. Күп)** | **II** | Урман һәм йорт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | 1. Дидактик уен: «Хайваннарның балаларын тап» («Әнисенә булыш») «Хайваннар турында сөйлә» . Схема ярдәмендә эш<br>2. Сүзле уен: «Серле китап» (Бу нәрсә? Кайда яши?)<br>3. Дидактик уен: «Ярый – ярамый» | | хайваннарының рәсемнәре (зур, кечкенә) уенчыклар. Серле китап |
| 9 | ___________<br>___________ | **Сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя төзү**<br>1. Картина белән эш «Яз килә».Дидактик уен: «Мин урманга бардым» (Пиктограмма белән хикәя төзү | **III** | «Яз килә», картинасы. Пиктограммалар |
| 10 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Әдәбият һәм фольклор**<br>1. Картина белән эш «Мин башлыйм, син дәвам ит»<br>2. Дидактик уен: «Тәрҗемәче»<br>3. Сүзле уен «Мин артист»(рәсем күрсәтелә, шигырь сөйләргә, яисә җыр җырларга тәкъдим ителә) | **IV** | Төрле сюжетлы рәсемнәр |
| 11 | ___________<br>___________<br>___________ | **Ана телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**<br>Дидактик, үстерешле, хәрәкәтле, сүзле уеннар. Пиктограммалар белән эш. Картина өстендә эш. | **V** | Алда күрсәтелгән күрсәтмә материаллар |

**УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ. ТАТАР БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН КОРРЕКЦИОН ЭШ**

И туган тел, и матур тел!!!

| № | БАЛА ИСЕМЕ, ФАМИЛИЯСЕ ТӨРКЕМ САНЫ | ТЕМА<br>ЭШ ТӨРЛӘРЕ<br>(УЕННАР, КҮНЕГҮЛӘР, БИРЕМНӘР) | ҮТКӘРҮ (АЙ) | КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛ |
|---|---|---|---|---|
| 1 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Үзең турында сөйләү**<br>1.Ситуатив күнегүләр: «Танышабыз»<br>2. Схема, пиктограммалар ярдәмендә эш:<br>«Үзең турында сөйлә» – бала чәчәк таҗын ала, үзе турында сөйли чәчәкне ясый) | **X** | Серле чәчәк (чәчәк таҗлары) пиктограммалар |
| 2 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Ягымлы сүзләр**<br>1. Дидактик уен: «Дөрес әйт»<br>2. Сюжетлы – рольле уен «Ашханәдә», «Әбидә кунакта»<br>3. Хәрәкәтле уен: «Чылбыр» | **X** | Сюжетлы – рольле уеннар өчен атрибутлар |
| 3 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Уенчыкка боерык бирә алу: бир, кил, утыр, бас, ал, аша, йөгер.**<br>1. Сюжетлы – рольле уен «Куянны сыйла», «Кибет»<br>2. Хәрәкәтле уен: «Талчыбыгым»<br>3. Санамышлар.<br>4. Тел шомарткычлар: «Ю – Ю – Ю» | **XI** | Уеннар өчен атрибутлар Серле тартма (уенчык, савыт-сабалар, кием яшелчә, һ.б.) |
| 4 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Бирелгән сорауларга дөрес җавап бирү (кем? нәрсә? нишли?).**<br>1. Картинкалар буенча әшләү «Гаилә»<br>2. Җыр «бу өй матур, бу өй зур»<br>3. Дидактик уен:«Бу кем? Бу нәрсә? Нишли?»<br>4. Дидактик уен: «Бу нәрсә? Нинди?» (уенчыклар)<br>5. Хәрәкәтле уен: «Кәрзинеңдә нәрсә бар?»<br>6. Табышмак әйтеш: «Табышмак әйтәм, җаваб тап» | **XI** | Табышмак җавапларын табу өчен ярдәмче уенчык, рәсемнәр Гаилә кешеләре рәсемнәре. |
| 5 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Рәсем, әйберләр күрсәтелә. Нәрсә? Нинди? соравына җавап бирү.**<br>1. Хәрәкәтле уен: «Песи, нинди төс?»<br>2. Дидактик уен: «Бу нәрсә? Нинди?»<br>3. Ситуатив күнегүләр: «Безнең дуслар» (хайваннар) | **XII** | Уенчыклар (йорт, урман хайваннары) |
| 6 | ___________<br>___________ | **Предметларны санау**<br>1. Дидактик уен: «Кем күбрәк җыя» | **I** | Сюжетлы рәсемнәр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ___________<br>___________ | 2. Дидактик уен: «Бер һәм күп»<br>3. Сүзле уен: «Бармакларны сана»<br>4. Картинкалар буенча әшләү «Гаилә»<br>5. Җыр «Бу өй матур, бу өй зур» | | Санау өчен уенчыклар. Гаилә кешеләре рәсемнәре |
| 7 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Гади җөмләләр төзү**<br>1. Картинкалар буенча әшләү «Яшелчә бакчасында»<br>2. Сюжетлы – рольле уен «Шифаханә», «Кибет»<br>3. Схема (пиктограммалар) ярдәмендә эш: «Үзең турында сөйлә»<br>4. Табышмак әйтеш: «Табышмак әйтәм, җавабын тап»<br>4. Хәрәкәтле уен: «Чылбыр» | **II** | Табышмак җавапларын табу өчен уенчык, рәсемнәр. Яшелчә мулялары. иктограммалар |
| 8 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Уенчык турында сөйләү**<br>1. Схема ярдәмендә эш: «Уенчыгың турында сөйлә»<br>2. Ситуатив күнегүләр: «Без уйныйбыз»<br>3. Сюжетлы – рольле уен «Уенчыклар кибете» | **III** | Сюжетлы – рольле уен өчен атриутлар. Уенчыклар. (зур, кечкенә) |
| 9 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя төзү**<br>1. Картина белән эш «Язгы урман»<br>2. Пиктограмма ярдәмендә хикәя төзү<br>3. Дидактик уен: «Дәвам ит»<br>4. Сүзле уен «Белмәмешкә булыш» | **IV** | Картина «Язгы урман», пиктограммалар |
| 10 | ___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **Иллюстрацияләр буенча, әсәрнең исеме сорала.**<br>1. Картина белән эш «Мин башлыйм, син дәвам ит»<br>2. Дидактик уен: «Тәрҗемәче»<br>3. Рәсем эчтәлеге буенча әңгәмә<br>4. Ситуатив күнегүләр: «Табын янында» | **IV** | Төрле сюжетлы рәсемнәр Табын янында – савыт-сабалар |
| 11 | ___________<br>___________<br>___________ | **Ана телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**<br>Алда күрсәтелгән дидактик, үстерешле, хәрәкәтле, сүзле уеннар.<br>Пиктограммалар белән эш. Картина өстендә эш. | **V** | Алда күрсәтелгән күрсәтмә материаллар |

**ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ ТАТАР БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН ИНДИВИДУАЛЬ - КОРРЕКЦИОН ЭШ**

**«И, ТУГАН ТЕЛ, И МАТУР ТЕЛ!»**

| БАЛАНЫҢ ИСЕМ, ФАМИЛИЯСЕ ТӨРКЕМ САНЫ | ТЕМА, БУРЫЧЛАР УЕННАР, КҮНЕГҮЛӘР, БИРЕМНӘР | ҮТКӘРҮ ВАКЫТЫ | ИСКӘРМӘ |
|---|---|---|---|
| ___________<br>___________<br>___________<br>___________<br>___________ | **«Уенчыклар»**<br>1. Дидактик уен «Синең исемең ничек?» (танышу) Ягымлы сүзләрне кабатлау.<br>2. Дидактик уен «Бу нәрсә?» (курчак, машина, куян, туп)<br>3. Дидактик уен «Нинди?» (Туп кечкенә.Машина зур. Курчак матур. Куян йомшак) | **IX** | |
